**ТАТАР ТЕЛЕ**
Казанда ничек кулланыла?
> 2

**АКЧАГА УРЫН БАР**
Авылларда җыеннар уза
> 2

**НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ**
Татарстан Республикасы бюджеты турында законнар
> 3

**ШАМКАЙНЫ САГЫНУ**
Аның һәр хәрәкәте үлчәнелгән, уйланылган иде
> 4


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 175 (28757) | Чәршәмбе | 1 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131


# АЛАР БЕРКЕМНӘН КИМ ТҮГЕЛ

**Инвалидлар ункөнлеге**

**Язмышларына үпкәләмичә, кайчак әле башкаларга үрнәк булып та яшиләр. Физик мөмкинлекләре чикләнсә дә, алар алдында киртәләр юк. Моның шулай икәнлегенә, үзләре белән сөйләшкәч, тагын бер кат инанасың.**

Балтач районының Кариле авылында гомер итүче Лилия Мөбарәкҗанова да беркайчан сер бирми. Авылдашлары гына түгел, районның социаль яклау бүлегендә дә кызның уңышлары турында горурланып сөйлиләр. Лилия исә үзе сүзгә саран булып чыкты. «Тыйнак бала ул. Ә үзенең кулыннан килмәгән эше юк. Сәхнәдән дә төшми ул», – ди Балтач районының социаль яклау бүлеге җитәкчесе Алсу Гатиятуллина.

Лилияне 5 нче сыйныфта укыганда машина бәрдерә. Шуннан гарипләнеп кала. Быел республика буенча уздырылган «Абилимпикс» бәйгесендә катнашып, пешекчеләр арасында 1 урынны алган. Озакламый үз көчен Мәскәүдә сынап караячак икән.

– Мине әнием ялгыз үстерә, һәр уңышым өчен аңа рәхмәтле. Тормышта югалып калмавыма да сөенәм. Райондагы «Фикердәш» клубына йөрим. Кул көрәше белән шөгыльләнү көч бирә. Спортта зур уңышларга ирештем, – ди Лилия.

«Татар-информ» агентлыгында узган очрашуда Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр хакында башкалар белергә тиеш, дигән фикердә. Ул бигрәк тә авыру бала үстерүче әниләргә рәхмәтле. Министр сүзләренчә, республикада соңгы елларда өлкәннәр арасында инвалидлык алучылар кимесә, балалар арасында бу сан арта.

– Республикада 272,5 мең физик мөмкинлеге чикләнгән кеше яши. Шуларның 16,5 меңе – балалар, – диде ул. – Сабыйлардагы авыруларны иртәрәк белү өчен бөтен шартлар тудырыла. Болай эшләгәндә, без күп кенә авыруларны вакытында күреп, аларны булдырмый да кала алабыз. Тернәкләндерү үзәкләрендә авыру бала үстерүче әти-әниләргә махсус белем дә бирәләр. Әгәр әти-әни дә баласы белән шөгыльләнә икән, ул очракта дәвалануның нәтиҗәсе күбрәк тә күренә.

Министрның әлеге сүзләре белән ДЦП авырулы кызын тәрбияләүче Рәзилә Мәхмүтова да килешә.

– Бала авыру туды, дип елап утырырга кирәкми. Үзем дә яшьлек белән белмичә, күп күз яше түктем. Алга, бары тик алга барырга кирәк. Әни кеше, баласына кирәк булгач, өйрәнә икән ул. Кая барсам, шунда белгечләр янына кереп, балага массаж ясарга да өйрәндем. Тернәкләндерү үзәкләренә дә барабыз, өйдә вакытта да тик тормыйбыз. Мин балама сәгатьләр буе күнегүләр ясатам, – ди ул.

Татарстанда берничә төрле диагнозы, сәламәтлегендә күп кенә кимчелекләре булган 499 бала бар икән. Алар өйдән чыкмый, министрлык, өйләренә килеп, социаль хезмәт күрсәтүне оештыра.

ak-bars.ru / Илнар Тәхбәтов

Эльмира Зарипова акыл ягыннан кимчелеге булган, интернатларда яши торган кешеләргә дә тукталды. Үз фатирлары да бар, әмма алар анда ничек яшисен белми, гап-гади тормыш шартларына ияләнмәгәннәр. Шуңа күрә интернатларда мондый кешеләрне тормышка әзерлиләр. Дәрвишләр бистәсендә урнашкан психоневрологик диспансерда без моны үзебез дә күреп кайткан идек. Анда махсус бүлмәне өй итеп ясаганнар. Физик мөмкинлеге чикле кешеләргә газ кабызырга, ашарга пешерергә өйрәтәләр. Кибеттә ипи белән сөт сатып алырга да булышалар. Министр, тормышка өйрәтә торган бүлмәләр «Идел» тернәкләндерү үзәгендә дә эшли башлады, дип хәбәр итте.

– Мөмкинлеге чикләнгән 89 кеше биредә махсус курслар үтте. Барысының да үз фатирында яшисе килә. Шунысы сөенечле: курслар узганда ике авыру парлашып куйды. Аларга яшәү икеләтә җиңелрәк булачак, – ди ул.

Авыру кешене карау җиңел түгел. «Демография» илкүләм проекты кысасында тормышка ашырылучы «Озак вакытлы ярдәм күрсәтү» проекты буенча якыннарын караучы 2 меңнән артык кешене укытып чыгарганнар. Эльмира Зарипова, республикада физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләргә барлык шартлар тудырылган, ди.

– «Абилимпикс» бәйгесендә күп кенә талантлар ачыла. Бәйгедә катнашкан кешеләрнең күбесе соңыннан эшкә урнаштырыла. Пандемиягә бәйле шартларны үтәп, мәдәни чаралар да үткәрелә. Озакламый «Кулга-кул тотынышыйк», «Татарстан энҗесе» исемле фестивальләр узачак, – ди ул.

Татарстанның медицина-социаль экспертиза баш бюросы җитәкчесе Ригель Низамов, инвалидлык бирүне әле дә автомат рәвештә озайтып була, дип хәбәр итте.

– Пандемия башлангач та без инвалидлыкны 6 ай саен озайта башладык. Барысы да электрон рәвештә башкарыла. Беренче тапкыр мөрәҗәгать итүчеләргә дә инвалидлык авыру хакындагы документларга нигезләнеп бирелә. Әгәр алар группа белән килешми икән, безгә килергә дә мөмкин, – диде җитәкче.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

## Юл буйлары – гел агач

Татарстанда төзелеп килүче М12 автомобиль юлы буенда 1 миллионнан артык агач – нарат, чыршы, карагай, каен, имән һәм корычагач (ясень) утыртылган. Агач утырту эшләре Бөгелмә, Кайбыч, Лаеш, Югары Ослан, Питрәч, Биектау, Казан шәһәренең Авиатөзелеш, Мәскәү районнарында башкарылган. Шулай итеп, барлыгы 263 гектар мәйданда 164 урын яшелләндерелгән. Күрше Чуашстан республикасында әлеге юл буенда барлыгы 740 гектардан артыграк мәйданда 3 миллион чыршы, нарат, карагай һәм имән утыртылган. Быелга юл буен яшелләндерү эшләре тәмам. Исегезгә төшерәбез: 810 чакрым озынлыктагы түләүле Мәскәү – Казан автомобиль юлын 2024 елга төзеп бетерү күздә тотыла.

## *Финанс белемеңне тикшер*

Татарстанда яшәүчеләр Бөтенроссия онлайн зачетында финанс өлкәсендәге белемнәрен тикшереп карауга чакырыла. Бу хакта Россия банкы Татарстан бүлегенең матбугат хезмәте хәбәр итә. Анда финанс өлкәсендә мошенниклык, инвестиция, пенсия, банклар һәм аларның эшчәнлеге, салымнар, кулланучылар хокукларын яклау буенча аң-белемнәрне тикшереп карарга була. Онлайн зачет 16 декабрьгә кадәр дәвам итә. Ул 2 баскычка бүленгән. Беренчесе – төп баскыч – финанс мәсьәләләренә әле төшенә генә башлаучылар өчен исәпләнгән. Икенчесе – алга китүчеләр баскычы – банкның төрле хезмәтләреннән файдалану тәҗрибәсенә ия булган кешеләр өчен. Зачетта катнашучыларга 30 сорауга җавап бирергә туры киләчәк. Исемле сертификат (социаль челтәрләрдә нәтиҗә белән уртаклашу мөмкинлеге бирә) алу өчен, шуның егермесенә төгәл җавап табу кирәк.

Онлайн зачетта катнашу өчен «Всероссийский онлайн-зачет по финансовой грамотности» сайтында теркәлергә кирәк.

## Декабрь суык була

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ноябрь аенда Казанда аномаль җылы һава күзәтелде: температура уртача күрсәткечтән 7–8 градуска зуррак булды. КФУ метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев әйтүенчә, һава температурасының югары булуыннан тыш, явым-төшем буенча да тайпылыш күзәтелгән: кары-яңгыры бер ай эчендә нормадан ике тапкыр диярлек күбрәк яуган. «Сәбәбе – безгә чираттагы зур циклонның үтеп керүе. Көньяктан һава агымы яңгыр һәм җылы алып килде», – дигән ул. Тимур Әүхәдиев әйтүенчә, атна азагында Казанда янә суыта. Декабрь аенда һава температурасы хәтта нормадан түбәнрәк булачак.

**Сораштыру**

# Үзегезне бәхетле тоясызмы?

**Россиядә яшәүчеләрнең күпчелеге үзен бәхетле дип саный. Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге үткәргән сораштыруда катнашучыларның 84 проценты шулай дип белдергән. 14 проценты үзен бу исемлеккә кертми икән. «Бәхет күрсәткече» итеп россиялеләр үзләренең һәм якыннарының сәламәтлеген, яхшы эштә эшләүне, тормыштан канәгать булуны атаган. Сораштыруда катнашучыларның «бәхетсез»ләре үзләренең бу халәтен илдәге вакыйгалар, матди хәлнең начар булуы, гаиләдәге мәшәкатьләр белән аңлаткан.**

**Наил НАЗАРОВ, КФУ мөгаллиме, эколог:**
– Бәхетле булу күбесенчә күңел халәтенә бәйледер. Һәр мизгелдә бәхет дигәнең төрлечә тоела, әлбәттә. Тулаем алганда, мин үземне бәхетле кеше дип саныйм. Ике балам үсеп килә, алар исән-сау. Гаилә башлыгы буларак, күбрәк гаиләдәгеләрнең кәефенә, күңел халәтенә игътибар итәсең бит ул. Әгәр аларның барысы да яхшы икән, димәк, син дә бәхетле, күңел һәм җан тынычлыгы бар дигән сүз.

**Ләйсән ХӘКИМУЛЛИНА, журналист:**
– Бәхет өчен күп кирәкми, диләр. Әмма мин моның белән килешә алмыйм. Шәхсән миңа үземне бәхетле тояр өчен күп кирәк. Гади генә нәрсәләр ул, шулай да, санап китсәң, хәйран җыела. Беренче чиратта сүз әти-әни саулыгы, энем, сеңлемнең исәнлеге, туган йорт җылысы, якын дусларым, тормыш иптәшем, яраткан эшем булу, берникадәр мөстәкыйльлегем турында бара. Боларны бер «пазл» буларак карасак, бер генә элементы җитмәсә дә, күңел тынычлыгым югала. Ул очракта «ярый әле монысы бар», «ярый әле исән-сау» дип юанырга гына кала. Бүген бәхетле мин. Тик «пазл»га бер нәрсә җитеп бетми… Тиздән анысы да булыр дип өметләнеп йөрим менә.

**Ләйсән ШӘФИГУЛЛИНА, Арча районындагы Кышкар авылы мәдәният йорты җитәкчесе:**
– Курыкмыйча әйтә алам: мин бәхетле! Гаиләм, ике кызым бар. Кызларымның инде – үз тормышы. Кечкенәсе оныклар белән сөендерде. Яраткан кешең белән гаилә корып, аннан балалар табу да үзе бер бәхет бит ул! Яраткан эшем бар. 34 ел мәдәният өлкәсендә. «Бәхетле булырга нәрсә җитми?» – дигән сорауга җавап та бирә алмыйм. Шөкер, барыннан да канәгать. Дөньябыз тыныч, сугышлар юк. Бәхетле булуымның тагын бер сәбәбе: әти-әнием исән-сау. Аларга булышу, аларның рәхмәтен ишетү – шатлык.

**Фирдүс ТЯМАЕВ, Татарстанның атказанган артисты:**
– Без барыбыз да бәхетле яшәргә хаклы. Иртән торып, күзне ача алабыз икән, хәлләребез әйбәт дигән сүз. Ашарга – ризык, кияргә  кием бар икән, барысы да яхшы. Зарланырга яратмыйм. Зарланганнарын да. Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле мин. Ул миңа шатлыгын да, хәсрәтен дә бирә. Бәхетлемен!

**Мәдинә ХӘМИДУЛЛИНА, Кайбыч районындагы Кошман мәктәбе укытучысы:**
– Бәхет төшенчәсен төрле кеше төрлечә аңлатырга мөмкин. Дөрес, бәхетле булу өчен әти-әнинең булуы, ярату да, матди, рухи байлык та, сәламәтлек тә кирәк. Яшь барган саен бәхетнең янәшәдә икәнен аңлыйсың. Шөкер, сәламәтлегем, яраткан гаиләм, эшем бар, күрешкәч: «Исәнмесез, апа, хәлләрегез ничек?» – дип сораучы элегрәк укыткан укучыларым бар. Иртән мәктәп ишегеннән кергәч тә, хәзерге укучыларымның шат авазлары каршы ала. Аларның уңышлары да безне бәхетле итә.

**Сүзгә-сүз**



**Владимир ПУТИН, Россия Президенты:**

Алдагы атналарда яңа штаммның зыяны ни дәрәҗәдә җитди икәнлеге аңлашылачак. Әмма вирусның теләсә кайсы үзгәрешенә әзер торырга кирәк. Иң беренче чиратта тест һәм вакциналарның нәтиҗәлелеген даими рәвештә тикшереп торырга, инфекция таралуны киметү өчен төгәл алгоритмнар куллану зарур.
**(«Россия зовет!» форумындагы чыгышыннан)**

## ЯҢА ЕЛ ЧЫГЫМНАРЫ

**Яңа елны бәйрәм итүгә Россиядә яшәүче һәр кеше уртача 18,5 мең сум акча тотарга җыена. Бу суммага бүләк алу чыгымнары кермәгән. SuperJob порталы илнең иң зур шәһәрләрендә яшәүчеләр арасында уздырган сораштыру нәтиҗәләре әнә шундый. Бәйрәмгә айлык кереме 80 мең сумнан арткан кешеләр, ир-атлар күбрәк акча сарыф итәргә ниятли икән.**

ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕНӘ КАЙДА КҮПМЕ АКЧА ТОТАЛАР?

| | 2021 ел | 2020 ел | 2019 ел |
|---|---|---|---|
| Мәскәү | 23200 | 22600 | 21000 |
| С.-Петербург | 20400 | 20700 | 19500 |
| Красноярск | 19300 | 18700 | 20000 |
| Самара | 19300 | 20000 | 18600 |
| Омск | 19000 | 19200 | 18700 |
| Уфа | 18700 | 19300 | 18400 |
| Казан | **18400** | **17500** | **18000** |
| Чиләбе | 17400 | 16800 | 17300 |
| Новосибирск | 16200 | 16400 | 16000 |
| Волгоград | 14600 | 14300 | 15000 |

## *Һәр йортка – «Ватаным Татарстан»*

Без шундый исемдә акция башлап җибәрдек. Әти-әниегезгә, күрше-күләнгә, укытучыларыгызга, өлкәннәргә, күпбалалы гаиләләргә – кыскасы, күңелегез теләгән һәркемгә шәп бүләк ясап, газетага яздырыгыз әле!

Спас районы Иске Рәҗәп авылының ветераннар оешмасы җитәкчесе Флера Алишева фикеренчә, иң кадерле, иң зур бүләк – атнага дүрт тапкыр өеңә килеп торучы, йөз елдан артык тарихы булган «Ватаным Татарстан» газетасы.

«Һәр йортка – «Ватаным Татарстан» акциясенә кушылып, алар авыл җирлеге һәм фермер хуҗалыклары ярдәме белән Иске Рәҗәптә яшәүче иң өлкән яшьтәге 20 хезмәт ветеранын газетага яздырган да инде. Кырык елдан артык авыл китапханәчесе булып эшләгән Флера Алишева өлкән буынның кайсы газетаны аеруча үз итүен яхшы белә. «Ни булса да, иске дус яңаларыннан яхшырак», – ди ул, шаяртып.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

**Дөньяда**

## ИЗРАИЛЬ: «ОМИКРОН»НАН БАШКА ДА

Дөнья икътисадына һәм сәясәтенә коронавирусның «омикрон» штаммы басым ясавын дәвам итә. Штамм турында рәсми хәбәрләр каршылыклы. Бер яктан аны куркыныч, вакциналанган һәм бер кат авырган кешеләрне дә аямый торган дәһшәтле мутант дип тәкъдим итсәләр, икенче яктан, гаҗәп дәрәҗәдә җиңел уза торган чир китереп чыгара, шул сәбәпле куркырга кирәкми, дип тынычландыралар.

Бу каршылыклы хәбәрләрнең икесенең дә уртак кисешү ноктасын табарга була, әлбәттә. Көньяк Африка Республикасыннан алган хәбәрләргә караганда, андагы халыкның бер дә исе китми бу штаммга. Вазгыять анда бездәгедән бик аз аерыла. Әмма шулай да килешик: чир таралу бер дә күңелле нәрсә түгел, сакланырга кирәк.

Бикләнү һәм икътисади элемтәләрне өзү чирнең үзе кебек үк куркыныч нәтиҗәләргә китерә. Ливандагы кебек вазгыять килеп туарга мөмкин. Анда коронавирус турында уйламыйлар да бугай инде, чөнки бөлгенлек чиктән ашты. Битлекле һәм битлексез гыйсъянчылар юлларны биклиләр, шәһәр урамнарында машина көпчәкләреннән учаклар дөрли. Милли валюта үзенең кыйммәтен 90 процентка югалтты, хәерчелек дәрәҗәсе 80 процентны узып китте. Гомумән, хәзерге икътисадта сәер һәм аңлашылмый торган хәлләр җитәрлек. Бәрәңге игүе белән дан тоткан һәм аны үзенең милли ризыгы дип таныган Беларусьта «икенче икмәк» – дефицитта. Базарларда аның бәясе 77–90 процентка арткан. Хакы Россия, Украина һәм Польшадагыдан кыйммәтрәк. Ил бәрәңгене читтән сатып ала башлады.

Изоляция чараларын кертми булмый, билгеле, әмма локдаунга бик сак килергә кирәк. Ливандагы вазгыять туудан бер ил дә имин түгел.

Газета хәбәрчесе бүген, бары тик рәсми хәбәрләргә генә таянып, пандемиягә каршы иң аяусыз көрәш алып барган Израильдәге хәлгә анализ ясады. Бу ил вакциналаштыру дәрәҗәсе буенча беренче урыннарда тора, чит илдән килүчеләрне бик тикшереп кенә кертә, аз гына шик туучыларны да карантинга яба. Локдауннарны бик еш игълан итә. «Нәтиҗәләре ничек?» – дигән сорауга җавап эзлик.

Израильдә дулкыннар бик көчле бара гадәттә. Октябрьдә алар бик авырлык белән дүртенче дулкыннан котылдылар: авыручылар һәм үлүчеләр саны кимеде. Әмма бер-ике атна тынлыктан соң пандемия яңадан баш күтәрә. Үткән якшәмбедә илдә чир йоктыручылар саны арта башлады. Көнлек күрсәткеч – 506 яңа авыру. Израиль халкы татарстанлыларга караганда 2,27 тапкыр күбрәк. Җан башына бүлеп исәпләсәк, бу илдә авыручылар саны якынча бездәге кебегрәк. Татарстандагы вазгыятьне без катлаулы дип санасак, Израильдә уңай дип исәпләнә, чөнки дулкынның пигында көнлек авыручылар саны 5–6 меңгә җиткән чаклар бар иде. Алар хәзер яңадан «пик»ка таба бара. Шимбә көнне хастаханәгә салынучы 168 кешенең 128е авыр хәлдә. Гыйбриләр бишенче дулкынның башланып килүе турында рәсми рәвештә игълан итте. Илдә инде «омикрон»ны йоктыручылар саны арта. Гыйбри табиблары барысы да өч тапкыр вакцина ясатты, тик «омикрон»нан, күрәбез, имин түгелләр. «Галәм гүзәле» конкурсына барган бер чибәркәй дә Израильгә коронавирус алып кайтып бикләнеп утыра. Хәлләр менә шундый. «Омикрон»ның авыр нәтиҗәләргә китермәвенә өметләник инде.

**Россиядә**

## НЕФТЬ: ЧЫГАРУНЫ АРТТЫРЫП БУЛЫРМЫ?

Россия вирусолог-галиме Анатолий Альтштейн яңа штамм коронавирусны гадәти салкын тию дәрәҗәсендәге авыруга әйләндерәчәк дигән фараз ясый әнә. Сөенечле бу фараз тормышка ашса (тормышка ашу мөмкинлеге иллегә илле дип саныйк әйдә), дөнья икътисады җанлана башларга тиеш бит инде. «Кара алтын» чыгаруны арттыра башларга туры киләчәк. Дөрес, пандемиядән башка да зур кризис көтә безне. Әмма әлегә чимал күбрәк таләп ителәчәк, чөнки чыгаруны 2020 елда бик нык киметтеләр.

ОПЕК+ министрлары әлегә вазгыятьне өйрәнә һәм җир маен күбрәк сатарга бик ашыкмый. Тик АКШ һәм Көнбатыш дәүләтләре ягулыкны күбрәк сорап, көчле басым ясыйлар. 1–2 декабрьдә нефть сатучы төп илләр министрларының хәлиткеч очрашуы көтелә. Ул 29 ноябрьгә үк тәгаенләнгән иде, яңа штаммнан куркып чигерделәр. Очрашуда «кара алтын» чыгаруны арттыру мәсьәләсе хәл ителергә тиеш. Уңай хәл ителсә, Россиягә дә скважиналарны тулы куәткә эшкә җигәргә мөмкинлек туа. Әмма россияле нефтьчеләр бер юнәлештә кыенлык кичерәләр: томаланган скважиналарны яңадан сафка бастыру мөмкин түгел диярлек. Бу кварталда ук квота ай саен йөз мең баррельгә арттырылган иде инде, тик ноябрьдә бу мөмкинлекнең яртысы гына файдаланылган.

«Коммерсант» газетасы иң эре өч нефть компаниясе топ-менеджерларының сүзенә таянып, «кара алтын» чыгаруны арттыру өчен куәтләрнең җитмәвен хәбәр итә. «Роснефть» вице-президенты Эрик Лирон 12 ноябрьдә арттыруның хәлдән килмәвен әйтсә, «Лукойл» вице-президенты Павел Жданов потенциалның бетүен 24 ноябрьдә хәбәр итте. «Газпромнефть» җитәкчелеге дә ел ахырына куәтләрнең төкәнәчәген кычкырып әйтеп тора. Бу турыда инде җәй көне үк, ОПЕК+ квоталарны арттыргач, мәгълүм булган. Иске скважиналарны эшләтеп җибәрү өчен, бездә техник мөмкинлекләр һәм технологияләр юк. Безнең климат шартлары шундый: «кара алтын» агымын бер туктаттыңмы, яңадан кузгалту авыр. Ниндидер хикмәтле технологиясен эшләргә кирәк. Вәләкин илдә акчаны технологияләргә тоту гадәте юк диярлек. Галимнәр ач утыра, инженерлар аз ала. Бюджет «бәлеш»е ел саен «силовик»лар файдасына күбрәк киселә.

«Кара алтын» чыгаруны арттыруның бер генә юлы кала – яңа скважиналар бораулау. Бу, бердән, инвестицияләр таләп итә, икенчедән, яңа ятмалар табарга кирәк, өченчедән, техник җиһазлар да сорала. Менә соңгысын безнекеләр чит илдән сатып алырга гадәтләнгән иде. Санкцияләр хәзер ул мөмкинлекне чикләде. Белгечләр, бик тырышсак, нефть чыгаруны 300–500 мең баррельгә арттырып булыр, шуннан күбрәге өметсез, диләр. Россия Энергетика министрлыгының рәсми документлары да «кара алтын» чыгаруның елдан-ел кими барачагын күрсәтәләр. Әгәр кичекмәстән бораулауга керешмәсәк, 2022 ел башында ук арту түгел, кимү башланачак, дип әйтүче белгечләр дә бар.

zpravda.ru

# КАЗАНГА ТАТАР ТЕЛЕ КИРӘК!

**И туган тел!**

**Татар теле тормышның һәр өлкәсендә дә кулланыламы? Аның дәрәҗәсе нинди? Әгәр дәрәҗәсе түбән яки кайбер өлкәләрдә бөтенләй кулланылмый икән, мәсьәләне ничек хәл итеп була? Әлеге сорауларга җавапны Казанның Фатыйха Аитова исемендәге гимназиядә узган «түгәрәк өстәл»дә эзләделәр. Анда Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, Казан мэриясе вәкилләре һәм тел активистлары катнашты.**

Казан башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Гүзәл Сәгыйтова әйтүенчә, ел дәвамында берничә дистә проект гамәлгә ашырылган. Аларның барысы да татар теленең кулланылышын арттыруга, аның абруен күтәрүгә юнәлтелгән. Әлеге проектлар хакында авторлары сөйләде.

Әйтик, «Үз телем» проекты татар телен популярлаштыру буенча иң яхшы идеяләргә багышланган һәм анда теләге булган һәр кеше катнаша алган. Әлеге проектның приз фонды бер миллион сумны тәшкил иткән. «Үз телем» проекты идеясе авторы һәм иганәчесе Рөстәм Рамазанов әйтүенчә, җиңеп чыккан идеяләр уникаль, авторлар исә көчле потенциалга ия.

Активист, татар теле укытучысы Рашат Якупов халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләүчеләр өчен татар теле курслары турында сөйләде. Аның иң зур теләге – татар телен популярлаштыру хәрәкәте бер ел белән генә чикләнмәсен иде. Ул муниципаль хезмәт вәкилләре өчен оештырылган курсларга да, татар теле укытучылары өчен оештырылган семинарларга да тукталды. Соңгысы аеруча игътибарны җәлеп итте. Оештыручылар заманча укыту алымнарына өйрәткән әлеге семинарның даими булуын теләде.

– Укытучы буларак, үземнең дә белемне арттыруга ихтыяҗым зур. Татар теле укытучылары өчен мондый чаралар уза, ләкин барыбер җитәрлек түгел. Татар телен чит телләр кебек үк үтемле, кызыклы итәсе иде. Шул максаттан әлеге семинар оешты да инде, – диде Рашат Якупов.

Марат Әхмәтов аңа: «Бүгенге вазгыятьтә татар теле укытучыларының күңеле сүрелмиме?» – дигән сорау бирде. Комиссия рәисе әти-әниләрнең төрле булуын, татар телен укытуның нәтиҗәлелегә мәктәпнең дәрәҗәсенә берничнди йогынты ясамавын, мәктәп директоры ихлас татар җанлы булмаса, аңа татар теле кирәкмәвен дә аңлавын җиткерде. Рашат Якупов исә, демотивациянең көчле булуын әйтте, әмма синең эшеңне күрә белгән мәктәп директоры булганда, татар телен укытуга дәүләттән дә ярдәм сизелгәндә, өмет бар, дип җавап бирде.

Татар телен популярлаштыруда милли поезд да уңышлы булган (Казан метросының бер поезды вагоннары милли рухта бизәлүе турында без язып чыккан идек. – **Ред.**). Татарча шундый алымнар автобус һәм башка җәмәгать транспортларында, тукталышларда кулланылса иде, дигән фикерләр әйтелде. Паркларда үткәрелеп килгән чаралар, фестивальләр турында да сүз булды. Марат Әхмәтов йомгаклап, Комиссиянең югалтуга таба барган тенденцияне туктатып булмасмы, рухи бушлыкны тутыру өчен чаралар оештырасы иде дигән максат белән эшләве турында әйтте:

– Мәктәп-бакчаларны йөреп чыккач, минем күңелемдә җылылык артты. Ник дигәндә, тел бетә, дип сөйләшүчеләр бик күп, шул ук вакытта конкрет эшләр башкаручылар да шактый. Казанга татар теле кирәк! Бу мәсьәләдә безнең сезнең белән байтак эшлисебез бар. Зур проблемаларның берсе – татар бакчалары, татар мәктәпләре торышы. Алар туксанынчы елларда оешса да, биналары 70–80 елларда ук төзелгән. Әти-әни баласын мәктәпкә яки балалар бакчасына биргәндә, эчтәлегенә дә, тышкы сурәтенә дә карый. Милли мәктәпләрне капиталь ремонтлау программасын да булдырырга кирәк.

Ул шулай ук киләсе елда дүрт балалар бакчасында прогимназия проекты эшли башлаячагы турында хәбәр итте. Бу – баланы татар гимназиясенә балалар бакчасыннан ук әзерли башлау дигән сүз.

Казан мәктәпләрендә 2021–2022 уку елында татар телен туган тел буларак укучыларның 55,45 проценты өйрәнә. Укучыларның 44,07 проценты туган тел буларак урыс телен сайлаган.
Татар телен барлыгы 82,4 мең укучы өйрәнсә, урыс телен туган тел буларак 65,5 мең укучы укый. 695 укучы (0,48%) туган тел дәресләрендә башка телләрне өйрәнә. Татар балаларының 83 проценты татар телен сайлаган, 17 проценты исә – урыс телен. Урыс балалары арасында 34 проценты – татар телен, 66 проценты урыс телен өйрәнә.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

# Нәтиҗәләрне гыйнвар башында көтәсе

**Күбрәк булыр дип көткән идек. Статистика федераль дәүләт хезмәтенең Татарстан буенча территориаль органы (Татарстанстат) җитәкчесе Наталья Гатауллина җанисәптә онлайн рәвештә катнашучылар турында сөйләгәндә шулай дип белдерде. Рәсми саннардан күренгәнчә, республика халкының 17 проценты илкүләм халык санын алуда «Дәүләт хезмәтләре» порталы аша катнашкан.**

Хәтерләсәгез, җанисәптә онлайн рәвештә катнашучылар саны буенча Татарстан Идел буе төбәкләре арасында беренче урынга чыкты. Әмма Татарстанстат белгечләре күбрәккә өмет иткән. «Җанисәптә «Дәүләт хезмәтләре» порталы аша катнашучылар күбрәк булыр дип уйлаган идек», – диде идарә җитәкчесе Наталья Гатауллина. Һәркемнең кул астында интернетка тоташкан кесә телефоны, гаджеты булган заманда бу ысул иң җайлысы кебек. Пандемия шартларында бигрәк тә. Әмма республика халкы җанисәптә өйгә килгән сан алучы сорауларына җавап биреп яки стационар участокка барып катнашуны өстенрәк күргән. Статистика белгечләре, моның сәбәпләрен ачыклап, махсус тикшеренү уздырырга җыена.

– Без икенче этапка – мәгълүматларны эшкәртү эшенә керештек. Быелгы халык санын алуның беренче нәтиҗәләре 2022 елның гыйнвар азагында билгеле булачак. Төп нәтиҗәләр 2022 елның декабренә әзер булыр дип көтелә, – ди Наталья Гатауллина.

Идарә башлыгы сүзләренә караганда, тиешле вакытын тулысынча эшләп чыккан сан алучыларның барысы да килешүдә күрсәтелгән суммадагы хезмәт хакын алачак. Әмма алар арасында коронавирус йоктыру сәбәпле сан алучы булып ахыргача эшләп бетерә алмаучылар да бар икән. Андыйларга акча башкарылган эш сәгате һәм күләме нигезендә түләнәчәк. «Казначылыкка акча күчерелде. Сан алучы булып эшләгән кешеләрнең күбесе хезмәт хакын алды инде. Кайберәүләр акча күчәргә тиешле исәп-хисап счетын дөрес күрсәтмәгән. Аларга хезмәт хакы соңрак күчәчәк. Контролер һәм уполномоченныйлар да килешү нигезендә акча алачак», – дип ышандырды Наталья Гатауллина.

Сан алучы булып эшләүчеләр үзләренә бирелгән планшетларны кире идарәгә кайтарган. Наталья Гатауллина сүзләренә караганда, республикада җанисәп вакытында бер генә планшет югалу, ватылу очрагы да теркәлмәгән. Халык санын алу барышында ун елга бер килә торган әлеге мөһим вакыйгада катнашудан баш тартучылар да булган. «Алар турында мәгълүмат административ чыганаклардан алыначак. Дөрес, анда барлык сорауларга да җавап табып булмаячак. Әйтик, алар аша кешенең яшәү шартлары турында мәгълүмат туплап булмаячак», – диде идарә башлыгы.

Яшелчә ник кыйммәтләнә? Хөкүмәт йортында узган брифингта азык-төлек бәяләре турында да сүз булды. Татарстанның икътисад министры урынбасары Роман Әмирханов сүзләренә караганда, республикада яшелчә, җиләк-җимеш хаклары өч күренешкә бәйле рәвештә арта.

– Яшелчә, җиләк-җимеш бүген дөрестән дә кыйммәтләнде. Аларның хакына, иң беренче чиратта, быелгы корылык, иртә килгән көз, яшелчә һәм җиләк-җимешләрнең үзкыйммәте, юл чыгымнары арту йогынты ясый. Вазгыятьне җайга салу өчен чаралар күрелә. Республикада авыл хуҗалыгы ярминкәләре уздырыла, социаль әһәмиятле юнәлешләргә субсидия бирү оештырылды. Моннан тыш федераль дәрәҗәдә дә чаралар күрелә. Монополиягә каршы федераль хезмәтнең республика буенча идарәсе белән берлектә уздырылган тикшерү барышында да яшелчә, җиләк-җимешкә бәяләрне үзара килешеп арттыру очраклары ачыкланмады, – ди министр урынбасары.

Еш кына азык-төлек хаклары фәлән сумга артты, дигән хәбәрне ишеткәч, кибет киштәсенә карыйсың да аптырап каласың. Чынлыкта теге яки бу товарның бәясе рәсми рәвештә игълан ителгән саннан  күбрәк арткан була. Наталья Гатауллина бу мәсьәләгә дә ачыклык кертте. «Без әйткән рәсми саннар билгеле бер төркем товарлар нигезендә исәпләп чыгарыла. Статистикада дөнья күләмендә килештерелгән методология бар. Бәяләр әнә шуның нигезендә исәпләнә. Шуңа күрә кибеттәге бәяләр рәсми рәвештә игълан ителгән саннар белән чагыштырганда күпкә кыйммәтрәк кебек тоелырга мөмкин», – ди идарә җитәкчесе.

Сүз уңаеннан, республикада азык-төлек бәяләренең көнлек үзгәрешен Татарстанстат идарәсенең рәсми сайтына (https://tatstat.gks.ru/) кереп күзәтеп барырга мөмкин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

# АКЧАНЫҢ КЕРЕР УРЫНЫ БАР

**Үзара салым**

**Пандемия һәр нәрсәгә үз кагыйдәләрен кертте. Башка елларда гөр килеп уза торган авыл җыеннары да быел салмак кына, тыныч кына уза. Хәер, үзгәрешләр инде узган ел ук башланган иде.**

Ноябрьдән башлап республиканың һәр авылында халык җыелып, узып баручы елга йомгак ясап, киләсе елга планнар барлый. «Татарстан муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясенең матбугат үзәге хәбәре буенча, җыеннар киләсе елның февраленә кадәр дәвам итәчәк. Республиканың күпчелек район, авылларында җыеннар узган инде. Илдәге вазгыятьне истә тотып, быел да тавыш бирүләр этаплап уздырыла. Зуррак авылларда урамы-урамы белән генә җыялар, кайбер җирләрдә халыкны чакырып тормыйча, җаваплы кешеләр өйдән-өйгә кереп, кешеләрнең фикерен белешеп йөри.

Мәгълүм булганча, мондый җыеннар вакытында халык үзара салым җыю турында фикер алыша, эшлисе эшләрне барлый. Җыелган акчаның күпчелеге, гадәттә, юл эшләре (шул исәптән күпер) өчен тотыла. Шулай ук җирлек территориясен, зиратларны карап тотуга, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм башка мәсьәләләрне хәл итү өчен зур ярдәм дип кабул итә моны халык.

Рәсми мәгълүматларга караганда, татарстанлыларның күпчелеге бу программага уңай карый. Соңгы елларда аңа ышаныч артуын саннар да сөйли. Мәсәлән, 2015 елда үзара салым программасы 799 авылда гамәлгә ашырылса, 2020 елда 878е катнашырга теләк белдергән иде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Чүпрәле районының Шланга авылы җирлеге башлыгы Илдар Якупов әйтүенчә, алар авылында җыеннар узган инде.

– Пандемия булу сәбәпле, 60 яшьтән өлкәнрәкләрнең өйләренә бардык. Калганнар мәдәният йортына куар-кодлар белән керде. Залны да 50–60 проценттан артык тутырмаска кирәк иде, – диде ул.

Үзара салым акчасына килгәндә, халыкның хәлен искә алып, бәяне күтәрмәскә кирәк дип карар кылганнар. Димәк, киләсе елда да халык 500әр сум акча тапшырачак.

Без бу авылга кайтып, су проблемасы турында язып та чыккан идек. Әлеге мәсьәләне хәл итәргә үзара салымнан җыелган акчаның да ярдәме тигән.

– Халык акчасына ясалган проект расланды. Киләсе елга авылга су керәчәк, Аллаһы боерса. Киләсе елда җыелачак акчага да урын бар. Юлларына таш түшәлеп бетмәгән урамнарыбыз бар. Җыелачак акча шул максатларга тотылачак. Авыл уртасындагы төп коены да төзекләндерербез, дип ниятләп торабыз, – диде авыл җирлеге башлыгы.

Әлки районының Түбән Әлки авыл җирлегенә барлыгы дүрт авыл керә. Башлык Фәрит Садриев әйтүенчә, әлегә икесендә җыеннар узган.

– Халык җыеннарга, үзара салымга ияләште инде. Шуңа күрә очрашулар тыныч, бер-беребезне аңлашып уза. Узган ел 600 сум җыйган идек, быел 700 сумга күтәрергә булдык. Халыкка рәхмәт, берсүзсез ризалаштылар, хупладылар. Чөнки һәр нәрсәнең бәясе артты. Ә безнең эшлисе планнар шактый. Юлларны төзекләндереп бетерү, су торбаларын карау, зиратларны тәртипкә китерү. Шулай ук һәйкәлләребез дә искерде. 60–70 нче елларда эшләнгән һәйкәлләр урынына яңаларын эшләп кую теләге бар. Быел иң күп халык яшәгән Түбән Әлкидән башласак, киләсе елларда калганнарында дәвам итәрбез дип торабыз. Бер авылда балалар мәйданчыгы юк иде. Анысы да кайтты. Урын билгеләп, урнаштырып кына куясы калды, – диде Фәрит Садриев.

Менә шулай, илдәге вазгыятькә карамыйча, авыл халкы алга таба планнар кора, киләсе елда эшлисе эшләрен барлый.

Зөһрә САДЫЙКОВА

## БУРЫЧЛЫ БУЛМАСЫН БАЛА!

Балигъ булмаган бала ниндидер милеккә ия булган очракта, аның өчен салым түләү бурычын әти-әнисе башкара.

Шуңа күрә Салым федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе республикада яшәүчеләргә бала өчен салым түләү максатында аңа «Шәхси кабинет» булдырырга киңәш итә.

Хәзер бала өчен салымны ата-ананың «Шәхси кабинеты» аша гына да түләргә мөмкин. Ата-ананың «Шәхси кабинеты»ның «Салымнар» бүлегендә пәйда булган исемлеккә балигъ булмаган балаларны кертергә мөмкин. Шуннан исемлектәге бала өчен үзегезгә уңайлы ысул: банк картасы, онлайн-банк аша салым түлисе генә кала.

**БАЛАНЫ ӘТИ-ӘНИСЕНЕҢ «ШӘХСИ КАБИНЕТЫ»НА ӨСТӘҮ ӨЧЕН:**

✓ баланың «Шәхси кабинеты»н булдырырга. Моның өчен аның паспорты яки туу турында таныклыгы белән теләсә кайсы салым органына мөрәҗәгать итәргә;

✓ ата-ананың «Шәхси кабинеты»нда «Профиль» бүлегенең «Семейный доступ» битенә, баланың «Шәхси кабинеты»на запрос юллап, баланы өстәргә;

✓ баланың «Шәхси кабинеты»на күчәргә дә, тиешле төймәгә басып, җибәрелгән запросны расларга кирәк.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
тарафыннан 2021 елның 25 ноябрендә кабул ителде

**1 статья**

1. 2022 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 300 032 686,5 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 324 046 421,4 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын 24 013 734,9 мең сум итеп.

2. 2023 елга һәм 2024 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2023 елга 305 631 470,4 мең сум һәм 2024 елга 312 954 274,6 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2023 елга 327 249 400,6 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 7 950 000,0 мең сум итеп, һәм 2024 елга 333 838 024,9 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 16 710 000,0 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын 2023 елга 21 617 930,2 мең сум һәм 2024 елга 20 883 750,3 мең сум итеп.

3. 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

1. 2023 елның 1 гыйнварына:

1) Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 85 581 377,6 мең сум итеп, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 16 513 000,0 мең япон иенасы, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 16 513 000,0 мең япон иенасы күләмендә расларга.

2. 2024 елның 1 гыйнварына:

1) Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 85 104 578,0 мең сум итеп, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 16 513 000,0 мең япон иенасы, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 16 513 000,0 мең япон иенасы күләмендә расларга.

3. 2025 елның 1 гыйнварына:

1) Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 84 627 778,5 мең сум итеп, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 16 513 000,0 мең япон иенасы, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 16 513 000,0 мең япон иенасы күләмендә расларга.

4. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән ихтимал булган гарантия очраклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен үтәүгә каралган Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2022 елга 11 559 100,0 мең сум, 2023 елга 11 559 100,0 мең сум һәм 2024 елга 11 559 100,0 мең сум күләмендә расларга.

5. 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары программасын әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

6. 2022 елда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бердәм бюджет счетында калган акчаларны тулыландыру өчен бюджет кредитлары җәлеп итү юлы белән Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашуларын башкару хокукын бирергә.

**3 статья**

Татарстан Республикасы бюджетында 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60[1] статьясындагы 2 пункты нигезендә 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәр бүлү нормативларын әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

**5 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясы нигезендә 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына һәм турыдан-туры кууыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына акцизлардан җирле бюджетларга күчерелә торган түләүләрне дифференциацияләнгән нормативларын билгеләү өчен кулланыла торган нормативларны әлеге Законга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

**6 статья**

1. Акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционер җәмгыятьләренең идарә органнарындагы дәүләт вәкилләре, 2021 ел нәтиҗәләре буенча чиста табыштан файдалану һәм дивидендлар түләү мәсьәләләре буенча акционер җәмгыятьләренең идарә органнары (директорлар советы, күзәтчелек советы, акционерларның гомуми җыелышы) тарафыннан карарлар кабул ителгәндә, акцияләр буенча дивидендларны 2022 елның 1 сентябренә кадәр (әгәр җәмгыять уставында башка срок билгеләнмәгән булса) ел йомгаклары буенча чиста табыштан кимендә 30 процент күләмендә акчалата түләү өчен тавыш бирергә тиеш.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының 2021 ел йомгаклары буенча салымнарны түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң калган өлеше 2022 елның 1 июленә кадәр әлеге табыштан 30 процент күләмендә күчерелә дип билгеләргә.

**7 статья**

1. 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Законга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге Законга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

3. 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге Законга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2022 елга 16 010 404,9 мең сум, 2023 елга 16 789 084,8 мең сум һәм 2024 елга 17 754 072,6 мең сум күләмендә расларга.

5. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасы күрсәткечләренә 2022 елда үзгәрешләр кертү өчен әлеге статьяда расланган, бюджетлар чыгымнары классификациясенең «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлегендәге «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлекчәсе буенча каралган бюджет ассигнованиеләре составындагы резервланган акчаларны түбәндәгечә бүлү нигез булып тора дип билгеләргә:

1) оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымын түләүгә 2022 елга 1 783 448,9 мең сум, 2023 елга 1 796 887,4 мең сум, 2024 елга 1 796 895,4 мең сум күләмендә;

2) каты коммуналь калдыкларны чыгару буенча йөкләмәләрне үтәүгә 2022 елга 98 204,3 мең сум, 2023 елга 98 204,3 мең сум, 2024 елга 98 204,3 мең сум күләмендә;

3) бюджет өлкәсе учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруга 2022 елга 5 990 989,5 мең сум, 2023 елга 6 263 772,4 мең сум, 2024 елга 6 562 193,3 мең сум күләмендә;

4) аерым категорияләр гражданнарга социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыруга 2022 елга 1 040 000,0 мең сум, 2023 елга 1 081 600,0 мең сум, 2024 елга 1 124 864,0 мең сум күләмендә;

5) гражданнарның ихтыяҗлы салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын башкаруга 2022 елга 1 000 000,0 мең сум, 2023 елга 1 000 000,0 мең сум, 2024 елга 1 000 000,0 мең сум күләмендә.

**8 статья**

Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга – товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә әлеге Законда каралган субсидияләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелә.

**9 статья**

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44[10] статьясы нигезендә 2022 елда, 2023 һәм 2024 еллар план чорында җирле бюджетлардан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен әлеге Законга 9 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44[10] статьясы нигезендә җирле бюджетлардан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле субсидия күләме, бер кешегә исәпләгәндә, аерым муниципаль берәмлек өчен финанс хисабы елында җирле бюджетның бер кешегә исәпләп чыгарылган салым керемнәре (түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән исәпкә алмыйча) һәм бер кешегә исәпләп чыгарылган салым керемнәре 1,3 тапкыр арттырылган уртача дәрәҗәсе арасындагы аерманың 2022 елда – 3 процентын, 2023 елда – 5 процентын, 2024 елда 5 процентын тәшкил итә дип билгеләргә.

**10 статья**

1. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен түбәндәгечә расларга:

1) 2022 елга – 14 687 315,3 мең сум;

2) 2023 елга – 15 411 842,7 мең сум;

3) 2024 елга – 16 340 890,2 мең сум.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дотацияләрне 2022 елда 14 017 230,0 мең сум, 2023 елда 15 034 856,1 мең сум, 2024 елда 16 115 341,2 мең сум күләмендә физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары алмаштыра.

3. 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүлүне һәм физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең шул дотацияләрне алмаштыра торган өстәмә нормативларын әлеге Законга 10 нчы кушымта нигезендә расларга.

4. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен билгеләгәндә муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителеше иң түбән дәрәҗәсе критерие буларак кулланыла торган күрсәткечне 2022 елга – 2,264, 2023 елга – 2,264, 2024 елга 2,264 итеп билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләрне исәпләгәндә кулланыла торган әлеге муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү чыгымнары белән бәйле буенча шәһәр, авыл җирлекләренең, авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерийларын күрсәткечен түбәндәгечә билгеләргә:

1) шәһәр җирлекләре буенча: 2022 елга – бер кешегә исәпләнгәндә 1 527,6 сум, 2023 елга – бер кешегә исәпләнгәндә 1 575,4 сум, 2024 елга – бер кешегә исәпләнгәндә 1 639,6 сум;

2) авыл җирлекләре буенча: 2022 елга – бер кешегә исәпләнгәндә 279,0 сум, 2023 елга – бер кешегә исәпләнгәндә 245,3 сум, 2024 елга – бер кешегә исәпләнгәндә 245,4 сум.

**11 статья**

1. 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бюджетара трансфертлар бүлүне әлеге Законга 11 – 41 кушымталар нигезендә расларга.

2. 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен финанслауның максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субсидияләр исемлеген әлеге Законга 42 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга конкурс нигезендә муниципаль берәмлекләр арасында бүленә торган субсидияләрне, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары исәбеннән субсидияләрне һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондлары исәбеннән бюджетара трансфертлар булган субсидияләрне бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фонды исәбеннән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фонды исәбеннән бюджетара трансфертлар булган субвенцияләрне муниципаль берәмлекләр арасында бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлекләр арасында бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

**12 статья**

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминиятләштерүгә иминият кертемнәрен түләү өчен җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен 2022 елга 16 221 650,5 мең сум, 2023 елга 16 873 693,7 мең сум, 2024 елга 17 551 868,5 мең сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар күләмен 2022 елга 8 915 716,1 мең сум, 2023 елга 9 038 045,6 мең сум, 2024 елга 9 150 822,4 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

1) мәҗбүри медицина иминиятенең нигез программасында билгеләнмәгән медицина ярдәменең өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә 2022 елга 1 725 983,5 мең сум, 2023 елга 1 752 090,1 мең сум, 2024 елга 1 765 114,1 мең сум күләмендә;

2) «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән очракларда чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә 2022 елга 7 189 732,6 мең сум, 2023 елга 7 285 955,5 мең сум, 2024 елга 7 385 708,3 мең сум күләмендә.

3. Әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертлар 2022 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына ай саен күчерелә дип билгеләргә.

**13 статья**

Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2022 елга 34 233 092,5 мең сум, 2023 елга 36 449 929,4 мең сум, 2024 елга 37 108 079,1 мең сум күләмендә расларга һәм аларны тиешенчә 2022, 2023 һәм 2024 елларга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә.

**14 статья**

Инвестиция салым кредитларын бирүгә юнәлдерелә торган акчаларның иң чик күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

2022 елга –100 000,0 мең сум;

2023 елга –100 000,0 мең сум;

2024 елга –100 000,0 мең сум.

**15 статья**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары 2022 елда Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз, моңа Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләренә яңа функцияләр яисә вәкаләтләр бирелүгә бәйле шундый карарлар кабул итү очраклары керми.

2. Җирле үзидарә органнарына 2022 елда муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәүне тәкъдим итәргә.

**16 статья**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җирле бюджетларны финанслашу (аларны финанс белән тәэмин итү) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган мондый бюджетара трансфертларны җирле бюджетлар акчаларын алучыларның чыгымнары буенча акчалата йөкләмәләрне түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә күчерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы вәкаләтләрен тапшыру турында карарларны Федераль казначылык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кабул итәләр дип билгеләргә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бюджетара трансфертлар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

**17 статья**

Татарстан Республикасы бюджетында түбәндәгеләрдән алына торган бюджетара трансфертларны һәм кире кайтарылмый торган акчаларны әлеге Законга 43 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга:

1) федераль бюджеттан 2022 елда 53 823 786,0 мең сум, 2023 елда 52 342 075,1 мең сум, 2024 елда 50 598 702,5 мең сум күләмендә;

2) дәүләт корпорациясеннән – Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фондыннан 2022 елда 260 415,3 мең сум, 2023 елда 51 019,3 мең сум күләмендә.

**18 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары Татарстан Республикасы бюджетын үтәүне, шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә муниципаль берәмлекләр бюджетларын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**19 статья**

Товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары буенча түләү өчен бирелгән, шушы контрактлар шартлары нигезендә 2021 елда түләнергә тиешле файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләренең, Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар булган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен 2021 елда кирәкле сумма чикләрендә бирелгән мондый бюджетара трансфертларны бирүгә бюджет ассигнованиеләренең, финанс белән тәэмин итү чыганагы юридик затларга субсидияләр булган субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен 2021 елда кирәкле сумма чикләрендә бирелгән мондый субсидияләрне бирүгә бюджет ассигнованиеләренең калган өлеше суммасыннан артмаган күләмдәге Татарстан Республикасы бюджетының 2022 елның 1 гыйнварына калган акчалары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, 2022 елда күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелә.

**20 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, суд эшчәнлеге турындагы, башкару эшчәнлеге турындагы һәм бөлгенлек (банкротлык) турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93[8] статьясындагы 4 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча бурычны җайга салу шартларын билгели торган, акчалата йөкләмәләрне үтәүне кичектереп тору яисә аларны өлешләп түләү турында, шулай ук бурычлыларны исәпләнгән пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләүдән тулысынча яисә өлешчә азат итү юлы белән йөкләмәләр күләмен киметү хакында ризалык килешүләре төзергә хокуклы.

**21 статья**

2022 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге чорга түбәндәгеләрнең гамәлдә булуын туктатып торырга:

1) «Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы беренче өлешенең (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 11; 2001, № 7 – 8; 2005, № 1 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән дәүләт ярдәмен финанслау өлешендә;

2) «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясындагы 12 өлешенең беренче абзацының (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 4 өлешенең беренче абзацының (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш);

4) «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы икенче абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 92 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Әлмәт муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен бирүдән тыш;

5) «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы икенче абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 10;

Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Азнакай муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Чистай муниципаль районы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен бирүдән тыш.

**22 статья**

Әлеге Закон 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

**Казан, Кремль. 2021 ел, 25 ноябрь**
**№ 86-ТРЗ**

Татарстан Республикасының әлеге Законы бөтен кушымталары белән PRAVO.TATARSTAN.RU адресында Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылган.

---

## 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
тарафыннан 2021 елның 25 ноябрендә кабул ителде

**1 статья**

1. 2022 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба шулай ук – Фонд) бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Фонд бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 63 778 600,6 мең сум, шул исәптән Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән 53 893 788,5 мең сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан 8 915 716,1 мең сум итеп;

2) Фонд бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 63 863 481,6 мең сум итеп;

3) Фонд бюджеты кытлыгын 84 881,0 мең сум итеп.

2. 2023 һәм 2024 еллар план чорына Фонд бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2023 елга Фонд бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 66 890 299,1 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән 9 038 045,6 мең сум, һәм 2024 елга 70 407 687,9 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән 9 150 822,4 мең сум итеп;

2) 2023 елга Фонд бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 66 890 299,1 мең сум һәм 2024 елга 70 407 687,9 мең сум итеп.

3. 2022 елга Фонд бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганакларын әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Фонд бюджетына керемнәр керүне түбәндәгечә билгеләргә:

1) 2022 елга әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә;

2) 2023 һәм 2024 еллар план чорына әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә.

**3 статья**

Фонд бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне түбәндәгечә расларга:

1) 2022 елга әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә;

2) 2023 һәм 2024 еллар план чорына әлеге Законга 5 нче кушымта нигезендә.

**4 статья**

Фонд бюджетын үтәгәндә әлеге Закон белән расланган күләмнәрдән тыш фактта алынган һәм максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар, әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә, Фонд бюджетының җыелма бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертеп, бюджетара трансфертлар бирү максатларына туры китереп, Фонд бюджеты чыгымнарын арттыруга җибәрелә дип билгеләргә.

**5 статья**

Фондның вакытлыча тотылмый торган акчаларын урнаштырудан алынган процент кереме күләмендәге акчалар Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруга җибәрелә дип билгеләргә.

**6 статья**

1. 2022 елга Фондның нормалаштырылган иминият запасы акчалары күләмен 6 997 859,0 мең сум итеп билгеләргә.

2. Нормалаштырылган иминият запасы акчалары түбәндәгеләргә җибәрелә дип билгеләргә:

1) Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруны медицина ярдәменә түләү өчен җитми торган акчаларны «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы 6 өлеше нигезендә иминләштерүче медицина оешмасына бирү юлы белән өстәмә финанс белән тәэмин итүгә;

2) иминләштерелгән затларга мәҗбүри медицина иминияте полисы бирелгән Россия Федерациясе субъекты территориясеннән читтә күрсәтелгән медицина ярдәме өчен исәп-хисаплар ясауга;

3) квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итүгә;

4) медицина оешмаларының табибларга һәм урта медицина персоналына хезмәт өчен түләүгә тотыла торган чыгымнарын финанслашуга;

5) гадәттән тыш хәл шартларында һәм (яисә) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу янаганда территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы белән билгеләнгән медицина ярдәме күләмнәре киметелүгә бәйле рәвештә медицина оешмаларына алып бетерелмәгән керемнәрен компенсацияләү чараларын финанс белән тәэмин итүгә.

**7 статья**

Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруда катнаша торган иминләштерүче медицина оешмалары өчен мәҗбүри медицина иминияте буенча эш алып баруга чыгымнар нормативын мәҗбүри медицина иминиятен финанс белән тәэмин итүнең җан башына дифференциацияләп исәпләнгән нормативлары буенча иминләштерүче медицина оешмасына кергән акчалар суммасыннан бер процент күләмендә билгеләргә.

**8 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3[1] пункты нигезендә 2022 елда Фонд бюджетының җыелма бюджет исемлегенә әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә үзгәрешләр кертү өчен өстәмә нигезләр булып түбәндәгеләр тора дип билгеләргә:

1) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибенә үзгәрешләр кертү;

2) 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3[2] пунктының өченче – алтынчы абзацларында каралган нигезләр буенча үзгәрешләр кертү;

3) 2022 елга бюджет ассигнованиеләрен әлеге Законда «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлеге, «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлекчәсе, «Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү» максатчан статьясы буенча каралган бюджетлар чыгымнары классификациясе чыгымнары төрләре арасында 2022 елда чыгымнарның күрсәтелгән бүлеге, бүлекчәсе һәм максатчан статьясы буенча бюджет ассигнованиеләрен файдаланганда экономияләү хисабына яңадан бүлү;

4) 2022 елда Фонд бюджетына әлеге Закон белән расланган 2022 елга бюджет ассигнованиеләре күләмнәреннән тыш медицина хезмәткәрләренә квалификация күтәрү программалары буенча өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итүгә җибәрелергә тиешле акчалар керү.

**9 статья**

Әлеге Закон 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

**Казан, Кремль. 2021 ел, 25 ноябрь**
**№ 87-ТРЗ**

Татарстан Республикасының әлеге Законы бөтен кушымталары белән PRAVO.TATARSTAN.RU адресында Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылган.

---


## Белдерү

Булатовой Ралией Илшатовной (квалификационный аттестат № 16-15-776, Республика Татарстан, 423603, г. Елабуга, пр. Нефтяников, д. 44, ralya90@mail.ru, 89172467786) подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельной доли Вазетдинова Азгата Азгаровича из паевого фонда СПК «Яхшый» с кадастровым номером 16:04:000000:243, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Актанышский муниципальный район, Верхнеяхшеевское сельское поселение.

Заказчиком работ является Вазетдинов Азгат Азгарович (РТ, Актанышский район, д. Нижнее Яхшеево, ул. Г.Тукая, дом 38. Тел.: 89196451201).

С проектом межевания можно ознакомиться в течение 30 дней со дня опубликования данного извещения, а также предоставить в письменном виде (относительно размера и местоположения границ земельного участка) обоснованные возражения, ежедневно с понедельника по пятницу с 8 до 17 час. по адресу: РТ, г. Елабуга, пр. Нефтяников, д. 44.

**ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА**

Кадастровым инженером Галимзяновым Ф.М., являющимся членом Саморегулируемой организации «Ассоциация кадастровых инженеров Поволжья» (уникальный реестровый номер 1413, номер в реестровой записи 30841 от 16.12.2016 г., 420101, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2-5, sinaf@mail.ru, (843) 514-63-63, № квалификационного аттестата 16-14-697 от 20.05.2014 г., СНИЛС 106-073-122-06), в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:172012:14, расположенного по адресу: Республика Татарстан, МО «г. Казань», г. Казань, Приволжский район, ул. Ручьевая, д. 3 проводятся работы по уточнению местоположения границы и (или) площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Саттарова Тамара Васильевна (Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2-5. Тел.: 89030618183).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 10 января 2022 г. в 10 часов 00 минут по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2-5, тел.: 514-63-63.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2-5, тел.: 514-63-63.

Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельного участка на местности принимаются с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2-5, тел.: 514-63-63 с 01.12.2021 г. по 10.01.2022 г.

Смежный земельный участок, с правообладателями которого требуется согласовать местоположение границ земельных участков с кадастровым номером: 16:50:172012:13, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Ручьевая, дом 1/17.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, нотариально заверенную доверенность на предоставление интересов юр. лица, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 года N 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).


## КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре, әнисе

**МИХАЙЛОВА Александра Афатимовнаның**

гомере вакытсыз өзелү сәбәпле, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы фракцияләр эшчәнлеген тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Оештыру идарәсе оештыру эше бүлеге баш киңәшчесе Михайлова Елена Александровнаның авыр кайгысын уртаклаша.

# Чәкчәк кенә димәгән

**Якын киләчәктә Татарстанда җәяүлеләр өчен махсус туристик маршрут барлыкка килергә мөмкин. Бу хакта Татарстанның Туризм буенча дәүләт комитеты башлыгы Сергей Иванов хәбәр итте.**

«Аны булдыру өчен Татарстанда да мөмкинлекләр җитәрлек. Табигатебез бик матур. Идел һәм Чулман буйларында тарихи һәм мәдәни яктан истәлекле урыннар, авыл туризмы объектлары шактый. Бүген туристлар табигатькә якын булуны өстенрәк күрә. Ил сукмакларыннан сәяхәт итү – туризмның экологик яктан иң чиста төрләренең берсе. Бик күп кешеләрне үзенә җәлеп иткән андый проектлар Канада, Испания, Израиль кебек илләрдә уңышлы гына эшләп килә», – дип белдерде Сергей Иванов.

Комитет башлыгы фикеренчә, мондый проектны Россиядә дә оештырып булыр иде. «Татарстан бу проектны беренчеләрдән булып тормышка ашыра ала. Тиешле юнәлешне сайлау гына җитми, эшмәкәрләр, җир участогы, шәхси сектор хуҗалары белән берлектә эш алып барырга да кирәк», – ди ул. Проектның Татарстанга кагылышлы өлеше эшләнгән инде. Әмма Сергей Иванов аның нидән гыйбарәт булачагын сер итеп калдырды. Бу хакта 5–7 декабрь көннәрендә Татарстанда узачак «Киләчәк ориентирлары» форумында җентекләбрәк сөйләргә җыеналар.

Сергей Иванов фикеренчә, Татарстанда аш-су туризмын да үстереп булыр иде. «Республиканың һәр районында моның өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Бездә үзенчәлекле ризык әзерләүче аш-су осталары бик күп бит. Без аларның кайберләрен белеп тә бетермибез. Дөнья күләмендә танылган унлап милли ризыгыбыз тирәсендә әйләнеп йөрибез. Чынлыкта исә безнең халыкның мәдәниятен, үткәнен күрсәткән ризыклар бик күп. Татарстанның һәр районында әнә шундый үзенчәлекләрне ачып, аларны туризм


vk.com

продуктына әверелдерергә кирәк», – ди комитет башлыгы.

Күптән түгел Мәскәү метросындагы бер поездны ил төбәкләре күренешләре белән бизәгәннәр. Алар арасында Казан да бар. Сергей Иванов моны республикага туристлар җәлеп итәрдәй тагын бер нәтиҗәле чара дип атый. «Мондый поездда көн саен бик күп кеше йөри. Татарстанга килгән туристларның күбесе – Мәскәүдән. Туризм буенча федераль агентлык мондый алымнар ярдәмендә төбәкләрдәге туризм үсешенә бик зур этәргеч ясый», – дип саный Сергей Иванов.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Белми калмагыз!

## «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

**БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ**

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

*Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.*

**АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ**

✓ мини-тракторлар;
✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

**ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50**

## ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ




1 ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ

2 ОНЛАЙН: vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

*Сөенечле хәбәр!*

*2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре*

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| П2435 атнага бер, җомга килә | ~~465 сум~~ 404,04 сум | П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә | ~~1000,92 сум~~ 859,08 сум |

*6–16 декабрь көннәрендә ташламалы бәяләр!*

Реклама 16+

# ШАМКАЙ

**Кызык бит, әйеме, шушы сүзне язып куйсаң, татар дөньясындагы бер шәхес күз алдына килә дә баса. «Халык артисты» дигән дәрәҗәсен дә, исемен әйтү дә кирәк түгел, дөнья йөзләрендә бер Шамкай ул. Минтимер ага Шәймиев әйтмешли: «Шамкаев булмаса, Шамкай да булмас иде». Беренче Президентыбыз «Шамкай» дигән сүзгә аерым мәгънә салып әйткән. Бу сүз һәркемне елмаерга мәҗбүр итүче җыелма бер образны гәүдәләндерә кебек тә әле.**

Без быел бакыйлыкка күчкән актер Рәшит Шамкаев турында ниләр беләбез соң? Берни дә белмибез. Хәтта сәхнәдәше Әзһәр Шакиров та аны соңгы юлга озатканда: «Без аны белеп бетермәгәнбез», – дигән. Бу әйтелергә тиешле сүзләр генә түгел, Әзһәр абый Рәшит Шамкаевның бөтен иҗат юлын, тормышын янә күз алдыннан үткәргәндер.

Әмма Шамкайны шактый ук якыннан белүче бар, ул – Алмаз Хәмзин. Һәм бу язма шактый ук дәрәҗәдә Алмаз белгән Шамкай турында булыр. Кеше белән тиз аралашса да, һәркем белән ачылып сөйләшмәгән Шамкай, ә Алмаздан күңелендә йөргәннәрне яшермәгән. «Биш татар» төркеме белән концертлар куеп йөри башлагач бигрәк тә якынаеп киткән алар. Тормышындагы иң күңелсез вакыйгалар турында да уйнап-шаяртып сөйли торган булган Шамкай.

Булачак артистның әле бала чагында ук, халыкча әйтсәк, «җүләрләр йорты»на эләгүен кем генә белә икән?! Авылда чагында җил-давыл чыгып, башы белән ташка бәрелгәч һәм җил белән ауган киртә арасында калгач, Рәшитнең мәктәптә укуы начарлана, үз-үзен тотышы үзгәрә. Шуннан моны психдиспансерга алып киләләр. Ә Шамкай бу хакта: «Җүләрләр йорты»нда мине шундук үз иттеләр. Миңа ертык бер тельняшка бирделәр дә, диспансер ишегалдында җир тирәли сәяхәт башладык. Тельняшка кию турында балачактан ук хыялланган идем, башым күккә тиде. «Сәяхәт» вакытында укымышлы җүләрләр ниндидер диңгез-океаннарны, утрауларны атый. Тора-бара безгә врачлар да кушыла башлады», – дип Алмазга көлә-көлә сөйләгән. Әлбәттә, «сары йорт»та озак тотмыйлар Рәшитне. Малай тиз терелеп чыга, мәктәптә әйбәт укый.

Аның артист булуы да кызыклы һәм гыйбрәтле. Авылга театр килүе, клубта «тере артист»ларның спектакль уйнаулары аңа шулхәтле нык тәэсир итә: Рәшит бөтенләй башка дөньяда, театр дөньясында яши башлый һәм үзенә: «Барыбер артист булам!» – дип сүз бирә. Казанга театр училищесына килә. Әмма комиссияне аның мишәрчәсе сагайта. Ул – Самара өлкәсе Камышлы районы Иске Ярмәк авылы егете. Сүз уңаеннан гына әйтим, шагыйрь Зыя Ярмәки, күренекле музыкант Рөстәм Вәлиев белән якташ ул. Чыкылдаган мишәр. Теле белән татар сәхнәсенә менү мөмкин эш түгел. Шулай да: «Ярар, телеңне төзәтербез», – дип училищега алалар Рәшитне. Әмма сәхнәгә менү һаман тоткарлана, театрда сәхнә эшчесе, китапханәче булып эшли. Көннәрдән бер көнне дигәндәй, моңа кечкенә генә роль бирәләр. Спектакль премьерасын Мәскәүдән килгән бер режиссер да карый һәм спектакльдән соң: «Теге егетне чакырыгыз әле!» – ди. «Теге егет» Рәшит була инде. Алмаз әйтүенчә, элек рольләрне бүлешкәндә күпмедер дәрәҗәдә Мәскәү сүзенә колак сала торган булганнар. Рәшиткә шушы шаукымның файдасы тия, «штатлы» артистка әйләнә ул.

Алмаз белән күпме баш ваттык, Шамкайның төп роль башкарганын беребез дә искә төшерә алмады. Нигездә эпизодик рольләрдә генә уйнаган икән бит егетебез. Урыс актерлары арасында «король эпизодов» дип йөртелгәннәре бар һәм аларны һәркем белә. Ни өчен? Чөнки алар берничә урында бер-ике җөмлә кыстырып та, йә бер сүз дәшмичә дә күңелгә кереп калырлык образ тудыра ала. Ирексездән театр, кино артисты Сергей Филипповны искә төшердек. Аның да төп рольләрне башкаруын хәтерләмибез булып чыкты.

«Татар-информ»

Ә исемен әйтүгә үзеннән-үзе елмаясы килә. Шамкай да шундый иде.

Алмаз аның турында сөйләгәндә дә көлми калмый, бүленә-бүленә көлә. Менә бер кәмит вакыйга. Нинди спектакль икәнен хәтерләми инде Алмаз, Камал театрында премьера бара. Шамкай һәрвакыттагыча эпизодта, «массовка»га якын күренешләрдә катнаша. Ул вакытта баш режиссер Марсель Сәлимҗановтан: «Мин нишләргә тиеш соң, Марсель Хәкимович?» – дип сорый. «Ну… чебен тоткан бул шунда…»

Сәхнәдә ниндидер комсомол җыелышы бара, үтә җитди мәсьәлә хакында бәхәс куба. Марсель Хәкимыч сүзеннән чыгып булмый бит инде, Шамкай кулы белән кизәнеп чебен тоткандай итә. Сәхнә читендәге бер өстәл янына утыра, чебенне ут яктысына куеп карый. Аннан соң бер канатын өзә. Чебен бер канат белән очып китәргә маташа. Шамкай аны бер канатыннан күтәреп аякларын тарткалый, тән төзелешен өйрәнгәндәй итә. Тамашачы комсомол җыелышы барганын бөтенләй оныта, йөзләгән күз бары Шамкайны гына күзәтә. Китә көлү! Тамашачыга ияреп артистлар да көлә башлыйлар, ятлаган текстларын онытталар.

Премьераны өзә бит бу Шамкай! Беренче рәттә утырган баш режиссер түзә алмыйча сикереп тора да: «Занавес!» – дип кычкыра. Пәрдә ябыла, ә халык һаман көлә. Баш режиссер пәрдә артына керә дә: «Ни кыланасың син, Шамкай, ә?!» – дип кычкыра.

– Соң, Марсель Хәкимыч, чебен тотарга үзегез куштыгыз бит!

Баш режиссер аның бу сүзенә каршы ни әйтергә дә аптырап: «Әй!» – дип кулын селки дә китеп бара.

Шамкай катнашкан спектакльләрдә мондый хәлләр әледән-әле булгалап тора. Кайберәүләр артистның кыланмышларын «маймыллану» дип тә кабул итәләр. Ә Алмаз: «Шамкай мизансценалар кую остасы иде, спектакль барганда иҗат итә иде ул, мондый талант һәркемгә дә бирелми», – ди.

Алмаз сөйләгән тагын бер гыйбрәт турында языйм әле. Авыл сәхнәсендә – сәхнә арты декорациясе. Актерлар тамашачы алдына чыгарга әзерләнә. Элек авыл сәхнәсендәге пәрдәләрдә тишек булмый калмый иде. Актерлар үзара сөйләшеп-киңәшеп, өс-башларын төзәткәләп халык алдына чыгарга әзерләнгәндә, Шамкай исә пәрдәдә бер тишек табып, залны күзәтә. Ыштанын күтәргәләп арт шәрифләрен кашып-кашып ала. Халык тәгәри-тәгәри көлә. Ә Шамкай, нигә көләләр болар, дигән сымак гаҗәпләнеп, бик җитди кыяфәт белән залга карап-карап ала. Халык тагын да катырак көлә башлый. Ярый әле бу очракта спектакль өзелми, күрәсең, тамашачы Шамкайның кыланмышларын шулай тиеш дип, режиссер куйган мизансцена дип кабул иткән. Ә Шамкай роле (нинди роль булсын инде ул!) онытылмаслык бер вакыйга булып истә кала.

Шамкай театрга бераз үпкәләп тә китте кебек. Әмма үпкәсен беркемгә дә сиздермәде, зарланып сөйләп йөрмәде. Дөрес, миңа «Биш татар»дан бик канәгать булуы, фатирлык акча эшләве турында әйткәне бар иде. Ярымподвалда яшәгәндә салкын тидереп, бер улы да үлгән иде аның. Монысын да сөйләп йөрмәде. Алмазга Болакның тимер коймалары өстенә ятып елавын сөйләгән булган үзе. Үтеп барган бер хатынның, аның янына килеп: «Нәрсә булды, сезгә нинди ярдәм кирәк?» – дип әйтүен дә сөйләгән. Әмма, гадәттә, бар кайгыларын күңеленә бикләп яшәргә тырыша иде ул. «Биш татар»да таланты тагын да ачылган. «Бездә бит артык чикләү, монысын сөйлә, тегесен сөйлә!» – дип әйтү юк иде. Шамкай бары тик: «Ничә минут чыгыш ясыйм?» – дип кенә сорый иде. Сәгатьләр буе сәхнә тота ала иде ул», – ди Алмаз. Әйе, тормышы бик җиңел булмаган Шамкайның, «Суфиям, Суфиям» дип кенә торган хатыны да үлеп киткән, анда да олы кайгысын яшерә алган. Сүз уңаеннан әйтик әле: Шамкайны Суфиясе янына, Арча районы Түбән Оры авылы зиратына җирләделәр.

Алмаздан: «Яңадан «Биш татар» төркеме оештырырга ниятләсәң, кемнәрне чакырыр идең?» – дип сорадым. Уйга калды ул. Яшьләр арасында талантлар бар, Шамкай урынына да кеше табып булыр, әмма ул инде Шамкай булмас иде», – диде Алмаз. «Биш татар»да, гомумән, һәрберсе шәхес, хәтта фикер каршылыклары булса да, алар бер йодрык иде һәм бу йодрыкта йомры сүзнең, сатираның көч-куәте сизелә иде. Ә хәзер, Алмаз фикеренчә, бүген чын юмор һәм чын сатираның урыны – ишек төбендә.

– Шамкай онытылырмы? – дим Алмазга.

– Бөтен кеше онытыла, зур җитәкчеләр дә, сәясәтчеләр дә. Ә Шамкай күңелләрдә озаграк сакланыр әле, – диде ул.

«Ни өчен?» – дип төпченеп тормадым. Ә озак саклану безгә, татар хәтеренә бәйле.

Мин үзем аны еш искә төшерәм. Төскә-биткә әллә ни булмаса да, ул: «Дөньяда миннән чибәр кеше юк, үзегез күреп торасыз», – дип тамашачыны көлдереп алырга ярата иде, кесәсеннән тарак чыгарып йөнтәс кашларын тарап алыр иде. Һәр хәрәкәте үлчәнгән, уйланылган иде аның. Татар театры, татар эстрадасының аерым бер чоры, һичшиксез, Шамкай исеме белән бәйле. Ә шәхесләрнең гомерен озайту безнең – каләм әһелләренең изге бурычы дип саныйм. Бу истәлекләрне дә шушы уй белән яздым.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

## ЭКОЛОГИЯ МИНИСТРЫ:

# «БЕЗ БАЛАЛАРДАН ӨЙРӘНӘБЕЗ»

**Табигатьне яратып**

**Казанның «Сәйдәш» мәдәният йортында мәктәп укучылары арасында уза торган республикакүләм «Экопатруль» бәйгесенә нәтиҗә ясадылар. Әлеге бәйге җиденче ел рәттән үткәрелә. Шушы вакыт эчендә укучылардан чүплекләр хакында 36 мең хәбәр килгән. Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков билгеләп үткәнчә, мондый бәйгенең асылында тәрбия ята.**

– Без бүләкләгән һәр баладан үрнәк алырга кирәк дип саныйм. Менә шундый табигатьне саклаучылар булганда киләчәк өчен тыныч була алабыз. Мәктәп укучылары үзләрен генә түгел, гаиләдәге өлкәннәрне, сыйныфташларын да артларыннан ияртә. Бер тапкыр бу бәйгедә катнашкан бала кулындагы чүбен җиргә атмый инде, – ди Александр Шадриков.

Министр әйтүенчә, укучылардан килгән хәбәрләр саны елдан-ел кими. 2019 елда 8 меңнән артык, 2020 елда – 5200, быел исә 2700 хәбәр килгән.

– Балалар экологиягә салкын караштa дигән сүз түгел бу. Чүплекләр саны кими – безне әнә шунысы сөендерә. «Экопатруль» бәйгесенең тагын бер уңай ягы – укучылар фотога һәм видеога төшереп җибәргән чүплекләр тиз арада юкка чыгарыла. Яшьләр белән дус булырга кирәк. Алар безгә бик ярдәм итә. Бары бергә эшләгәндә генә без экологияне саклый алабыз, – ди ул.

Пандемия аркасында узган ел үткәрелми калган «Экопатруль» җиңүчеләрен дә котладылар. Алар арасында чүплекләр хакында иң күп хәбәр юллаган Саба кызы Лиана Хәбирова да бар.

– Әлеге бәйгедә кечкенәдән катнашам. Башлангыч сыйныфта укыган чакта укытучым катнашырга тәкъдим иткән иде. Өйгә кайтып, әти белән әнигә әйттем. Аларга шул җитә калды. Сабада чүплек тапмагач, без атна саен республиканың төрле районнарына чыгып китә башладык. Беренче чүплекләрне Түбән Камага барып төшергән идек, – ди 6 нчы сыйныфта укучы Лиана.

Апасы Сабина да әлеге бәйгедә катнаша. Кызлар һәр елны призлы урыннар яулый.

– Безнең өчен нинди бүләк алуыбыз мөһим түгел. Без бит, бәйгедә катнашабыз дип, үзебез дә сизмәстән табигатьне чүп-чардан коткарабыз, – ди кыз.

Сарман районының Җәлил бистәсендә яшәүче Азалия белән Азамат Ханнановлар бәйгедә бишенче ел рәттән катнаша. Бу хакта әтиләре кайтып әйткән.

– Мин болай да балаларны табигатькә сакчыл карарга өйрәтеп үстерәм. Гаиләдә шулай куелган. Без һәрвакыт агач утыртабыз, тирә-якны җыештырабыз. Бу бәйге балаларга канат куйды. Җитмәсә, бүләкләре дә яхшы, – ди әтиләре Илнур.

Министр исә бәйгенең киләсе 2022 елда да дәвам итәчәген әйтте. Ул башка балаларны да актив булырга өндәде.

**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Тираж – 7387 данә**
**Гомуми тираж – 17167 данә**

**Газетага сертификат бирелде** Заказ 375

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

**www.vatantat.ru**

**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**

**89179270040**

**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР

**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-73, 222-09-67** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы
**222-09-67** – фән һәм мәгариф
**222-09-64** – әдәбият, сәясәт һәм дин
**222-09-66** – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
**222-09-67** – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+